ГЛАВА АЮСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**07.11.2024 ел** **№4**

**2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлеге Уставының 23 статьясына ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. 22.11.2024ел 10.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча урнашкан китапханә бинасында билгеләргә: ТР, Минзәлә муниципаль районы, Дружба торак пункты, Мәктәп урамы, 3 йорт.2025 елда үзара салымны кертү мәсьәләсе буенча Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыелышына тәкъдим ителгән мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлегенең Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә Сез ризамы?,1,2 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, күпбалалы гаиләләрдән тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1)Дружба торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш салу, зиратка юлны грейдерлау, эшләр өчен шартнамә буенча түләү);

2) Дружба торак пунктында су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина өчен тирәнлек насосын сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны Аю авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

5.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Минзәлә муниципаль районы
Аю авыл җирлеге башлыгы ______________А.М.Галимов